ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«27» август 2020 ел — № 645

**Арча муниципаль районында муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның әлеге гомуми белем бирү оешмаларында мондый укучылар саныннан 100 процентын түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру буенча чаралар исемлеген раслау турында**

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 15 гыйнварындагы (2020 елның 24 гыйнварындагы Пр-113 номерлы) Юлламасын гамәлгә ашыру буенча йөкләмәләр исемлегенең 5 пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм муниципаль белем бирү оешмаларында мондый укучылар саныннан 100 процентны тәэмин итүче укучылар өчен түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүгә 2020 елның 1 сентябреннән 2023 елның 1 сентябренә кадәр этаплап күчү зарурилыгы турында» 2020 елның 14 июлендәге 588 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 16 июлендәге 7601/20 номерлы хаты нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районында муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның әлеге гомуми белем бирү оешмаларында мондый укучылар саныннан 100 процентын түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру буенча чаралар исемлеген ("юл картасы") расларга (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә (С.П.Галимова) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә күрсәтелгән чараларны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Мөхәрәмовка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.Галимуллин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«27» август 2020 ел, №645
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында Арча муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру чаралары исемлеге (алга таба-юл картасы)**

| Юл картасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затлар | Вазыйфасы, фамилиясе, атасының исеме | Элемтә өчен телефон |
|---|---|---|
| Арча муниципаль районында юл картасы чараларын тормышка ашыру кураторы | Башкарма комитет җитәкчесе<br><br>И.Ә. Галимуллин | 422000, ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12<br>Элемтә өчен телефон:<br>8(84366)3-00-44<br>E-Mail: Ilshat.Galimullin@tatar.ru |
| Арча муниципаль районында юл картасы чараларын тормышка ашыруны оештыручы һәм контрольдә тотучы җитәкче | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МУ башлыгы Р.Д. Мөхәммәдияров | 422000, ТР, Арча шәһәре, Вәгыйзовлар ур., 11<br>Телефон: 8(84366) 3-24-98<br>E-Mail: arsk.rono@tatar.ru |
| Арча муниципаль районында юл картасын тормышка ашыру өчен җаваплы затлар | Мәгариф оешмалары җитәкчеләре | 422000, ТР, Арча шәһәре, Вәгыйзовлар ур., 11<br>Телефон: 8(84366) 3-24-98<br>E-Mail: arsk.rono@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Башкаручылар:<br><br>«Арча үзәк район хастаханәсе" ДАССОның баш табибы | Т.В. Бaһaветдинов | 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Комсомол ур., 32<br>Телефон: 8 (84366)3-16-03<br>E-Mail: Rail.Shakirov@tatar.ru |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | Р.Р. Мөхәрәмов | 422000, ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12<br>8(8436)63-00-44 |
| Инфраструктура үсеш бүлеге башлыгы | Р.В. Хәбибуллин | 422000, ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12<br>Телефон: 8(84366)3-12-44<br>Email: Rustem.Habib@tatar.ru |
| Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Биектау, Арча, Әтнә, Балтач районнарында территориаль бүлеге (Биектау ТО) башлыгы | Э.В. Салкова | 422701, Биектау районы, Биектау авылы, Полк урамы, 2г йорты, 1001 бүлмә<br>телефон: 8(84365) 3-15-01<br>E-Mail: rpn.arsk@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Мәгариф оешмалары җитәкчеләре | | |

| | | |
|---|---|---|
| Арча муниципаль районында 1 - 4 сыйныф укучыларын бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү буенча эшләрнең 100%ын тәэмин итү вакыты (башлану/тәмамлану) | Эш башлану датасы<br><br>01.09.2020 | Эшләрне тәмамлау датасы<br><br>31.08.2023 |

| № | Гомуми мәгълүмат | Төп күрсәткеч | | Фаразланган күрсәткеч | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Күрсәткеч | дата | 01.09.2020 | 01.09.2021 | 01.09.2022 | 01.09.2023 |
| 1.1 | Арча муниципаль районында башлангыч гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының гомуми саны | 36 | 01.09.2019 | 36 | 36 | 36 | 36 |
| 1.2. | Башлангыч гомуми белем бирү программасы буенча укучыларның гомуми саны | 2491 | 01.09.2019 | 2615 | 2680 | 2725 | 2750 |

2. Арча муниципаль районында юл картасы чараларын тормышка ашыруның максатлары, максатчан һәм өстәмә күрсәткечләре

| № | Максат, максатчан күрсәткеч, өстәмә күрсәткеч (төп) | Контрольлек итү дәрәҗәсе | Төп күрсәткеч | | Фаразланган әһәмият | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | күрсәткеч | дата | 01.09.2020 | 01.09.2021 | 01.09.2022 | 01.09.2023 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. | Максат: муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныф укучыларының түләүсез кайнар ризык белән тәэмин ителгән саны һәм өлеше (2023 елның 1 сентябренә 100%) | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МУ | 0% | 01.09.2019 | 100% | 100% | 100% | 100% |
| 2. | 1-4 сыйныф укучыларын мәҗбүри кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру буенча җәмәгать (ата-аналар) контроле гамәлгә ашырыла торган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының саны һәм өлеше (%) | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МУ | 36/ 100% | 01.09.2019 | 36/ 100% | 36/ 100% | 36/ 100% | 36/ 100% |

3. Юл картасы бурычлары һәм чаралары исемлеге

1 бурыч. 2023 ел нәтиҗәләре буенча 1-4 сыйныф укучыларын түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүдә 100% ка ирешү

| № | Бурычлар, нәтиҗәләр атамасы | Башкару срогы | Җаваплы башкаручы/ярдәмче башкаручы | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1.1. | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгында билгеләнгән тәртиптә менюны (ике варианттан да ким булмаган) килештерү, раслау | 2020 елның сентябре | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Татарстан республикасында бердәм меню кабул ителгәннән соң<br><br>Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МУ | Билгеләнгән тәртиптә килештерелгән меню булу |
| 1.2. | Укучыларны бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү мониторингы | Даими | «Мәгариф идарәсе» МУ һәм Арча муниципаль районы ата-аналар комитеты | Укучыларны туклану белән тәэмин ителешенә даими мониторинг |
| 1.3. | Азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм туклануны оештыру буенча хезмәт күрсәтүләргә контрольлек итүне оештыру һәм | Даими | Мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре | Азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм туклануны оештыру |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | үткәрү | | | хезмәте күрсәтүгә контрольлек итүне тәэмин итү |
| 1.4. | Муниципаль белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар санына карап, пешекчеләр һәм ризык әзерләү хезмәткәрләренең штат берәмлекләрен билгеләү | 2020 ел | "Мәгариф идарәсе" МУ, мәгариф оешмалары | Штат исемлеге булу |

2 бурыч. Белем бирү оешмаларын 1-4 сыйныфларда бушлай кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру өчен кирәк булган тиешле инфраструктура булдыру һәм җиһазлар белән тәэмин итү

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2.1. | Азык-төлек блогы һәм туклану залларына аудит үткәрү.<br>Азык- төлек бүлекләрендә суыткыч һәм техник җиһазларны эш халәтендә тоту.<br>Искергән һәм сафтан чыккан технологик һәм суыткыч җиһазларын этаплап алыштыру.<br>Азык-төлек бүлеге, инженерлык коммуникацияләре һәм башка урыннарга инвентаризация үткәрү | Ел саен | Арча муниципаль районы башкарма комитеты, "Мәгариф идарәсе" МУ, мәгариф оешмалары җитәкчеләре | Азык-төлек бүлекләре һәм ашханәләр торышының факттагы күрсәткечләре булу; проблемаларны билгеләү һәм аларны хәл итү механизмнарын формалаштыру |
| 2.2. | Мәктәп азык-төлек бүлекләренең һәм ашханәләрнең дәүләт һәм | Даими (ел саен) | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге | Муниципаль белем бирү оешмаларының |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | муниципаль белем бирү оешмаларының 1 - 4 сыйныф укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтүнең бердәм региональ стандартына (шул исәптән персонал белән тәэмин ителеш) туры килүен мониторинглау | | өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Биектау, Арча, Әтнә, Балтач районнары (Биектау ТО) территориаль бүлеге | 1-4 сыйныф укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтүнең бердәм региональ стандартына мәктәп азык-төлек бүлекләренең туры килү-килмәвен мониторинглау нәтиҗәләре нигезендә төбәк һәм муниципаль программаларга төзәтмәләр кертү |

3 нче бурыч. 1-4 сыйныф укучыларын мәҗбүри кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруны камилләштерү

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3.1. | Укучыларның туклануын оештыруга җәмәгать (ата-аналар) күзәтчелеген тәэмин итү.<br>Белем бирү оешмаларының ата-аналар комитетлары әгъзаларын җәлеп итеп, мәктәп укучыларының туклануын оештыру буенча тикшерүләр үткәрү | 2020 елның ноябре (алга таба квартал саен) | "Мәгариф идарәсе" МУ, белем бирү оешмалары җитәкчеләре | Укучыларның туклануын оештыруга җәмәгатьчелек (ата-аналар) контроле |
| 3.2. | «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә белем бирү оешмаларының | Даими | Белем бирү оешмалары | Балаларның туклануын |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | рәсми сайтларында балаларны тукландыруны оештыру шартлары, шул исәптән көндәлек меню турында мәгълүмат урнаштыру | | җитәкчеләре | оештыру шартлары турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү, шул исәптән көндәлек меню |
| 3.3. | Сәламәт туклану культурасын формалаштыру буенча мәгълүмати-агарту эшен оештыру.<br>Туклануны оештыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләр үткәрү.<br>Максатчан аудитория формалаштыру, балаларның һәм ата-аналарның сәламәтлеген саклау, сәламәт туклануны популярлаштыру буенча тематик чаралар үткәрү, мәктәп менюсы ризыкларын ашап карау, Туклану көне, укучылар өчен мәгълүмати бишминутлык уздыру. Һәр гомуми белем бирү оешмасында ата-аналар советы эшчәнлеге турында мәгълүмат стендын рәсмиләштерү | Даими | Белем бирү оешмалары җитәкчеләре | Укучылар туклануында файдалы гадәтләр формалаштыру |
| 3.4. | Белем бирү оешмаларында туклануны оештыруда катнашучы кадрларның: пешекчеләр, медицина белгечләре / диетсестра, туклануны оештыручыларны (җитәкчеләрне), туклануны оештыру өчен | Даими | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, белем бирү оешмалары | Әзерлек һәм квалификация күтәрү программалары булу. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | җаваплы мәгариф оешмаларында әзерләү һәм квалификациясен күтәрү. Мәктәп ашханәләрен кадрлар белән тәэмин итүне анализлау. Штат расписаниесе нигезендә кадрлар белән тәэмин ителеш. Азык-төлек бүлеге хезмәткәрләренең үз вакытында квалификациясен күтәрү | | җитәкчеләре, «Арча үзәк район хастаханәсе», Биектау, Арча, Әтнә, Балтач районнарында кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе территориаль бүлеге (Биектау ТО) җитәкчеләре | Белем бирү оешмаларын, мәктәп ашханәләрен туклануны тәэмин итү буенча квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү |
| 4 | «Юл картасы бурычлары һәм чаралары исемлеге" дигән 3 бүлектә һәр бурычка ирешүнең өстәмә күрсәткечләре | Мәгариф оешмалары җитәкчеләре | | |

**1 бурыч буенча күрсәткечләр 2023 елның 1 сентябренә 1-4 сыйныф укучыларын түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүдә 100% ка ирешү**

| №, | Максат, максатчан күрсәткеч, өстәмә күрсәткеч (төп) | Контрольлек итү дәрәҗәсе | Төп күрсәткеч | | Фаразланган күрсәткеч | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Күрсәткеч | дата | 01.09.2020 | 01.09.2021 | 01.09.2022 | 01.09.2023 |
| 1.1. | Билгеләнгән тәртиптә расланган һәм килештерелгән меню булган гомуми белем бирү оешмаларының саны һәм өлеше (%) | муниципаль | 36/ 100% | 01.09.2019 100% | 36/ 100% | 36/ 100% | 36/ 100% | 36/ 100% |

| | |
|---|---|
| **2 бурыч буенча күрсәткечләр белем бирү** | Җаваплылар: жирле үзидарә органнары катнашында Арча муниципаль |

| | |
|---|---|
| **оешмаларын 1-4 сыйныф укучылары өчен түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру өчен кирәк булган тиешле инфраструктура булдыру һәм җиһазлар белән тәэмин итү** | районы башкарма хакимияте органы мәгариф өлкәсе җитәкчеләре, мәгариф оешмалары җитәкчеләре |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **3 бурыч буенча күрсәткечләр 1-4 сыйныф укучыларына мәҗбүри кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру буенча җәмәгать контролен гамәлгә ашыру** | | Җаваплылар: җирле үзидарә органнары катнашында Арча муниципаль районы башкарма хакимияте органы мәгариф өлкәсе җитәкчеләре, мәгариф оешмалары җитәкчеләре | | | | | | |
| 3.1. | Укучыларның туклануын оештыруга җәмәгать контроле гамәлгә ашырыла торган гомуми белем бирү оешмаларының саны һәм өлеше (%) | муниципаль | 36/ 100% | 01.09.2019 100% | 36/ 100% | 36/ 100% | 36/ 100% | 36/ 100% |
| 3.2. | «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларда балаларны тукландыруны оештыру шартлары турында мәгълүмат урнаштырган мәгариф оешмаларының саны һәм өлеше (%), шул исәптән көндәлек меню | муниципаль | 36/ 100% | 01.09.2019 100% | 36/ 100% | 36/ 100% | 36/ 100% | 36/ 100% |
| 3.3. | Белем бирү процессында укучылар һәм ата-аналар белән сәламәт туклану культурасын формалаштыру буенча мәгълүмати-агарту эшен оештыру (әйе/юк) | муниципаль | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе |